ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 апрель 2020 ел № 1828

Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр Россия Федерациясенең илкүләм максатлары һәм стратегик үсеш бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы, «Сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» Федераль проекты нигезендә, Россия Федерациясе Президенты каршындагы стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар буенча Совет президиумы тарафыннан расланган 2018 елның 24 декабрендәге 16 номерлы «Сәламәтлек саклау» илкүләм проект кысаларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының финанс идарәсенә конкурста сайлап алуны узган кандидатларны укыту өчен чыгымнарга компенсация түләүгә шәһәр бюджетыннан 0113 бүлегендә (максатчан статья – 0920300) каралган акчаларны 2020 елдан башлап ел саен бүлеп бирүне күздә тотарга.

3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен грантлар алуга

конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 8 декабрендәге карарының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 14 апрелендәге
1828 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс (алга таба – конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурс, әлеге нигезләмәнең 19 пунктында күрсәтелгән конкурста сайлап алу критерийлары нигезендә, ел саен 1 августтан 15 августка кадәр үткәрелә.

2 бүлек. Комиссиянең эш тәртибе

3. Конкурс Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурс үткәрү буенча комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан үткәрелә.

4. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

5. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, җаваплы секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

6. Комиссия рәисе булмаган очракта, утырышны рәис урынбасары үткәрә.

7. Комиссиянең эш формасы булып утырыш тора.

8. Комиссия составының өчтән ике өлеше катнашкан очракта, комиссия утырышы тулы хокуклы санала.

9. Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия утырышын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия утырышына чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

3) комиссия утырышында карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәлә буенча фикер әйтергә;

4) конкурска тәкъдим ителгән документлардагы мәгълүматның дөреслеген раслау өчен тиешле оешмаларга запрослар ясарга.

10. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссия утырышында рәислек итә, аның эшен оештыра;

2) комиссия утырышы беркетмәләрен имзалый.

11. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы хокукларыннан файдалана, шулай ук комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара.

12. Комиссиянең җаваплы секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән

файдалана, комиссия эшен оештыра, шулай ук:

1) сәламәтлек саклау учреждениеләренә конкурс үткәрү турында хәбәр итә;

2) комиссия эшен башкара;

3) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне, шулай ук беркетмә алып баруны оештыра;

4) комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү вакыты һәм датасы турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

5) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

13. Комиссия карары тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, хәлиткеч тавыш хокукына комиссия рәисе, ул булмаган очракта аның урынбасары ия була.

14. Комиссия карары утырыш үткәрелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә комиссия рәисе яки аның әлеге утырышны алып баручы урынбасары һәм җаваплы секретаре тарафыннан имзалана.

15. Комиссия карары нигезендә конкурста сайлап алуны узган затларга ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында Башкарма комитет карары чыгарыла.

16. Әлеге нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән карар чыкканнан соң, конкурста сайлап алуны узган затлар комиссиягә әлеге нигезләмәнең 2 нче кушымтасында каралган форма буенча килешү төзү турында гариза җибәрәләр.

## 3 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

17. Конкурста катнашу хокукына югары медицина белеме алган һәм Россия Федерациясе территориясендә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы булган затлар ия.

18. Кандидатлар, конкурста катнашу өчен, 1 августка кадәр срокта, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 305 кабинет адресы буенча түбәндәге документларны җибәрәләр:

1) әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча конкурста катнашуга гариза;

2) беренчел аккредитация нәтиҗәләре;

3) шәхесне раслаучы документ күчермәсе;

4) югары медицина белеме турында документ күчермәсе;

5) медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларында хезмәт эшчәнлеген раслаучы документлар (оригиналлар һәм күчермәләр) (булганда);

6) шәхси казанышларны раслаучы башка документлар (булганда).

19. Кандидатларны сайлап алу комиссия тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

1) беренчел аккредитация нәтиҗәләре буенча баллар;

2) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе тарафыннан бирелгән мәгълүматлар нигезендә кандидатның ординатурада укырга планлаштырган белгечлеккә ихтыяҗ (ихтыяҗдан чыгып 0 дән 10 баллга кадәр);

3) кандидатның шәхси казанышлары:

- бик яхшы билгеләре булган билгеләнгән үрнәктәге документ (15 балл);

- Россия Федерациясе хезмәт законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланган медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларында гомуми эш стажы:

- урта медицина белеме булган медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларында бер елдан өч елга кадәр (10 балл);

- югары һөнәри белеме булган медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларында тугыз айдан ике елга кадәр (12 балл).

20. Исемлек конкурс баллары кимү тәртибендә ранжирлана.

21. Комиссия конкурс йомгаклары буенча чыгымнар өчен компенсация алу хокукына ия 10 (ун) кандидаттан торган исемлекне беркетмә белән раслый.

22. Кандидат, кабул итү турында приказ белән расланып, ординатурага бюджет нигезендә керү сәбәпле конкурста катнашудан язмача баш тарткан очракта, ординатурада уку чыгымнарын компенсацияләү хокукы алуга кандидатлар исемлеге конкурста сайлап алуны узмаган, ләкин иң күп балл җыйган кандидатлар арасыннан әлеге нигезләмәнең 21 пунктында күрсәтелгән санга җиткерелә.

23. Комиссия конкурста катнашуны түбәндәге очракларда кире кага:

1) әлеге нигезләмәнең 18 пунктына туры килми торган документлар тапшырылган;

2) тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат бар.

## 4 бүлек. Конкурсны финанслау

24. Конкурста сайлап алуны узган затларга чыгымнарны компенсацияләү түләве, чыгымнарны компенсацияләүгә килешү һәм дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесе белән түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә килешү төзелгәннән соң, конкурста сайлап алуны узган затның исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.

25. Компенсациянең күләме ординаторны укыту бәясенең яртысын тәшкил итә, әмма ординатурада уку программасы буенча ике ел уку дәвамында һәр ел өчен 80 (сиксән) мең сумнан артык түгел.

26. Башкарма комитет белән ординатурада уку программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында килешү төзегән зат, килешүне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән, яисә үз инициативасы буенча җитди сәбәпсез аны срогыннан алда өзгән очракта, ординатурада уку программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында төзелгән килешү шартлары нигезендә җавап бирә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 14 апрелендәге
1828 номерлы карарына
2 нче кушымта

Ординатура программасы буенча уку өчен түләү
чыгымнарын компенсацияләү турында килешү

Яр Чаллы шәһәре «____» ____________ 20___

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба Башкарма комитет дип атала, ____________________________________________________________________ нигезендә эш итүче ___________________________________________________ исеменнән бер яктан һәм

_____________________________________________________________________________,
(гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме),

алга таба Граждан дип атала, бергә Яклар дип аталучылар, Башкарма комитетның ______________ 2020 _____ номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге килешү нигезендә Граждан _____________________________________
(белем бирү оешмасының исеме)
тормышка ашырыла торган югары уку йортыннан соңгы белем бирү программасын - ___________________________ белгечлеге буенча ординатура программасын (алга таба- ординатура программасы) үзләштерергә, ординатура программасы буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узарга, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы һәм Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән медицина оешмасы ________________________________ (алга таба - медицина оешмасы) белән табиб - _______________________________ вазыйфасында эшләү турында хезмәт килешүе төзергә һәм мондый оешмада әлеге категория хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән эш вакытының нормаль дәвамлылыгы шартларында өч ел дәвамында төп эш урыны буенча хезмәт вазыйфаларын башкарырга бурычлы.

1.2. Әлеге Килешүдә билгеләнгән өч еллык эш срогын исәпләгәндә, Гражданның балага 3 яшь тулганчы аны карау буенча ялда булу чоры исәпкә алынмый.

1.3. Граждан тарафыннан белем бирү оешмасына ординатура программасы буенча уку өчен түләүгә акча күчерү турында түләү документлары белән расланган түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы килешү нигезендә, Башкарма комитет гражданга ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына уку бәясенең яртысы күләмендә, ләкин ординатура программасы буенча уку өчен бер елга 80 (сиксән) мең сумнан да артмаган күләмдә компенсация (алга таба - компенсация) бирергә бурычлы.

2. Якларның бурычлары

2.1. Граждан бурычлы:

2.1.1. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән белгечлек буенча югары

һөнәри белем өчен федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә ординатура программасын үзләштерергә.

2.1.2. Узган уку яртыеллыгынан соң килә торган айның 30 числосына кадәр Башкарма комитетка белем бирү оешмасында академик бурычның булмавын раслаучы документны, Граждан тарафыннан ординатура программасы буенча уку өчен түләүгә акча күчерүне раслаучы түләү документларын тапшырырга.

2.1.3. Фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, банк реквизитлары һәм әлеге килешүне үтәү өчен әһәмиятле булган башка мәгълүматлар үзгәрү турында, күрсәтелгән үзгәрешләр барлыкка килгәннән соң 10 календарь көн эчендә, Башкарма комитетка хәбәр итәргә.

2.1.4. Җитди сәбәпләр буенча (йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яшь тулганчы бала карау буенча ял, хәрби хезмәткә чакырылган очракта академик ял) Граждан укуын туктатып торуга китергән хәлләр барлыкка килү турында, шулай ук түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы килешүне өзү (туктату) һәм ординатура программасын үзләштерүнең норматив срогы тәмамланганчы Гражданны белем бирү оешмасыннан чыгару турында, әлеге хәлләр килеп чыккан датадан башлап 10 эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә Башкарма комитетка хәбәр итәргә.

2.1.5. Белем алу һәм квалификация турында тиешле документ алган көннән башлап ике айдан да соңга калмыйча медицина оешмасы белән табиб - ___________________________ вазыйфасында эшләү турында хезмәт килешүе төзергә һәм әлеге категория хезмәткәрләр өчен хезмәт законнары белән билгеләнгән эш вакытының нормаль дәвамлылыгы шартларында өч ел дәвамында төп эш урыны буенча хезмәт функцияләрен башкарырга, граждан ихтыярына бәйле булмаган хәлләр буенча (медицина оешмасына эшкә урнашуга комачаулаучы авырулары булу, Гражданны билгеләнгән тәртиптә I яки II төркем инвалид дип тану; гражданның үлеме) Граждан тарафыннан медицина оешмасы белән хезмәт килешүе төземәүдән тыш.

2.1.6. Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы килешү өзелгән (туктатылган) һәм ординатура программасын үзләштерүнең норматив срогы тәмамланганчы Граждан белем бирү оешмасыннан чыгарылган очракта, алынган компенсация акчаларын шәһәр бюджетына кире кайтарырга, граждан ихтыярына бәйле булмаган хәлләр буенча түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы килешү өзелүдән (туктатылудан) һәм Гражданны белем бирү оешмасыннан чыгарудан тыш.

Компенсация акчаларын кире кайтару, әлеге пунктта күрсәтелгән очрак килеп чыккан датадан башлап 60 көннән дә соңга калмыйча, акчаларны Башкарма комитетның исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарыла.

2.2. Башкарма комитет бурычлы:

2.2.1. әлеге Килешүнең 2.1.2 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән башлап 10 эш көне эчендә, Гражданның кредит оешмасында ачылган счетына түбәндәге реквизитлар буенча компенсация күчерергә:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

2.2.2. Табиб ___________________________________ вазыйфасында эшләү турында хезмәт килешүе төзеп, алган квалификациясе нигезендә Гражданны медицина оешмасына эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Граждан тарафыннан әлеге Килешүнең 2.1.5 пунктында каралган йөкләмә үтәлмәгән очракта, Граждан шәһәр бюджетына алган компенсациянең икеләтә күләмендә штраф түләргә тиеш.

Штрафны түләү, әлеге Килешүнең 2.1.5 пунктында күрсәтелгән срок чыккан датадан башлап 60 көннән дә соңга калмыйча, акча күчерү юлы белән башкарыла.

3.2. Гражданның медицина оешмасы белән төзелгән хезмәт килешүе аны төзегән датадан башлап өч ел узганчы өзелгән яисә туктатылган очракта, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы 1 бүлекнең 8 пунктында, 81 статьясындагы 1 бүлекнең 1, 2 һәм 4 пунктларында, 83 статьясындагы 1 бүлекнең 1, 2, 5, 6 һәм 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт килешүе туктатылган очраклардан тыш, Граждан шәһәр бюджетына фактта эшләнгән вакытны исәпкә алып, алынган компенсациянең икеләтә күләмендә штраф түләргә тиеш.

Штраф түләү, әлеге пунктта күрсәтелгән очрак килеп чыккан датадан башлап 60 көннән дә соңга калмыйча, акчаларны Башкарма комитетның исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарыла.

3.3. Әлеге Килешүне төзү һәм компенсация алу максатында Граждан тарафыннан дөрес булмаган яки ялган документлар һәм мәгълүматлар бирү фактлары ачыкланган очракта, Граждан алынган компенсациянең бөтен суммасын шәһәр бюджетына кайтарырга, шулай ук алынган компенсациянең икеләтә күләмендә штраф түләргә тиеш.

3.4. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү барышында нинди дә булса фикер каршылыклары яки бәхәсләр килеп туган очракта, Яклар эшне судка тапшырганчы, аларны сөйләшүләр юлы белән җайга салырга тиеш.

Әлеге Килешүнең 3.1, 3.2 пунктларында каралган очракларда штраф түләткәндә, Башкарма комитет Гражданга бозылган йөкләмәне, йөкләмә срогы чыгу чорын, түләтелә торган штраф күләмен, шулай ук акчаларны күчерергә кирәк булган реквизитларны күрсәтә торган язмача дәгъва җибәрә. Дәгъва тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән җибәрелә. Дәгъва, Килешү буенча дәгъва срогы чыкканчы, теләсә кайсы вакытта җибәрелергә мөмкин. Дәгъваларны карап тикшерү срогы - аны алган датадан башлап 10 календарь көн.

Ризалыкка ирешмәгән очракта бәхәсле мәсьәләләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә суд тәртибендә карала.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Әлеге Килешү ул Яклар тарафыннан имзаланган датадан башлап төзелгән дип санала һәм Яклар үз йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнгә кадәр гамәлдә була.

4.2. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча, әлеге Килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән, Яклар тарафыннан имзалана торган гади язма рәвештә бердәм документ төрендә кертелә.

4.3. Әлеге Килешү белән җайга салынмаган барлык очракларда, Яклар гамәлдәге законнарга таянып эш итә.

4.4. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде, аларның берсе Башкарма комитетта саклана, икенчесе имзаланган көнне Башкарма комитет тарафыннан Гражданга (аның вәкиленә) тапшырыла.

Якларның адреслары һәм реквизитлары

«Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ
423805, ТР, Яр Чаллы шәһәре,
Х. Туфан проспекты, 23
ИНН/КПП 1650135166/165001001 БИК
049205001
Счет: 40204810700000000050
ГРКЦ НБ РТ Россия Банкы
Казан шәһәре
БИК 049205001

Башкарма комитет
Җитәкчесе

_____________/ Ф. Ш. Салахов
м.у.

Граждан

______________________________________
Ф.И.А.и.

______________________________________
туган көне

______________________________________
паспорт мәгълүматлары

______________________________________

______________________________________
теркәлү адресы

______________________________________
элемтә өчен телефон

__________ / ______________________________

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г. К. Әхмәтова

Ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Конкурс комиссиясе рәисе
Ф.Ш. Салаховка

________________________________________

________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

Паспорт серия ________№________________

________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Теркәлү адресы __________________________

________________________________________
Элемтә өчен телефон номеры: _____________
________________________________________

Электрон почта адресы ___________________

Югары уку йортыннан соңгы ординатура белеме бирү программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурста катнашу турында гариза

Башкарма комитетның 20____ елның «____» _______________ «Уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә мине _____________________________________________________________
(белгечлекне күрсәтергә)
белгечлеге буенча югары уку йортыннан соңгы ординатура белеме бирү программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алу хокукына конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм.

Моның белән Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетына минем тарафтан ординатура программасы буенча укуны һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы медицина оешмасында хезмәт функцияләрен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында башка органнарга һәм оешмаларга бирү, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгълүмат системаларына кертү өчен кирәк булган персональ мәгълүматларымны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, үзенчәлекләрен бетерү, блокировкалау, бетерү, файдалану буенча гамәлләр башкаруны да кертеп, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Минем тарафтан эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге: фамилия, исем, әтиемнең исеме, туу датасы, җенес, гражданлык, шәхесне раслаучы документ турында мәгълүматлар, гаилә хәле, яшәү урыны (тору) адресы, телефон номеры, электрон почта адресы, белем турында, өстәмә әзерлек, арадаш аттестация нәтиҗәләре турында мәгълүматлар.

Әлеге Килешү ул имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турындагы килешүдә каралган йөкләмәләрне тулысынча үтәгәнгә кадәр гамәлдә була.

Килешү минем язмача гаризам нигезендә теләсә кайсы вакытта кире алынырга мөмкин.

Кушымта:
1.______________________________________________________________.
2.______________________________________________________________.
3. ______________________________________________________________.

«______» _______________20_____ел ____________________________________

имза, имзаның расшифровкасы

Ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Конкурс комиссиясе рәисе
Ф.Ш. Салаховка

______________________________________

______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

Паспорт серия _______№______________

______________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Теркәлү адресы ________________________

______________________________________
Элемтә өчен телефон номеры: ___________
______________________________________

Электрон почта адресы _________________

Югары уку йортыннан соңгы ординатура белеме бирү программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында килешү төзү хакында гариза

Башкарма комитетның 20____ елның «____» ______________ «Уку өчен түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә минем белән _____________________________________ белгечлеге буенча
(белгечлекне күрсәтергә)
югары уку йортыннан соңгы ординатура белеме бирү программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында килешү төзүегезне сорыйм.

Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында килешү ___________________________ № ___________________________________________
(түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында килешү төзү номерын һәм датасын күрсәтергә)
_________________________________________________________________ белән төзелде.
( белем бирү оешмасының исемен күрсәтергә).

Килешү нигезендә ординатурада уку бәясе елына ____________________________ сум.

Түләүне Россия кредит оешмасы аша _________________________________ ачылган
(кредит оешмасы исемен һәм реквизитларын күрсәтергә)
____________________________________________________ счетына башкаруыгызны сорыйм.

Моның белән Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетына минем тарафтан ординатура программасы буенча укуны һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы медицина оешмасында хезмәт функцияләрен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында башка органнарга һәм оешмаларга бирү, Яр Чаллы шәһәре

Башкарма комитетының мәгълүмат системаларына кертү өчен кирәк булган персональ мәгълүматларымны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, үзенчәлекләрен бетерү, блокировкалау, бетерү, файдалану буенча гамәлләр башкаруны да кертеп, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Минем тарафтан эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге: фамилия, исем, әтиемнең исеме, туу датасы, җенес, гражданлык, шәхесне раслаучы документ турында мәгълүматлар, гаилә хәле, яшәү урыны (тору) адресы, телефон номеры, электрон почта адресы, белем турында, өстәмә әзерлек, арадаш аттестация нәтиҗәләре турында, ординатурада уку өчен түләү чыгымнарына компенсация бирү турында килешү хакында, компенсация түләүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында мәгълүматлар.

Әлеге Килешү ул имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ординатура программасы буенча уку өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турындагы килешүдә каралган йөкләмәләрне тулысынча үтәгәнгә кадәр гамәлдә була.

Килешү минем язмача гаризам нигезендә теләсә кайсы вакытта кире алынырга мөмкин.

Кушымта:
1.________________________________________________________________.
2.
_________________________________________________________________.
3.
_________________________________________________________________.

«______» _______________20_____ел

_________________________________
имза, имзаның расшифровкасы

Башкарма комитетның
2020 елның 14 апрелендәге
1828 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен
квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен ординатура программасы буенча уку өчен
түләү чыгымнарына компенсация алуга конкурс үткәрү буенча
комиссия составы

1. Салахов Фәрид Шавкат улы - комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе;

2. Хәлимов Рамил Мәрван улы - комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;

3. Хөсәенова Альбина Шамил кызы - комиссиянең җаваплы секретаре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге консультанты (килешү буенча);

комиссия әгъзалары:

4. Борһанова Айгөл Әбүзәр кызы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);

5. Валгушева Гөлнара Илдус кызы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге башлыгы (килешү буенча);

6. Камалетдинова Ләлә Әнвәр кызы - Шәһәр Советының гражданнар сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе (килешү буенча);

7. Николаев Александр Николаевич - Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешү буенча);

8. Ревякина Анжелика Константиновна - «Республика медицина мәгълүмати-аналитик үзәге» ДАССУның әйдәүче юрисконсульты (килешү буенча).

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова